

Ел саен жир остендә хезмәт иткән барлык кеше Авыл хужалыгы конен яратып бәйрәм итә. Шулай, Кадошкино районы Мәдәният йортында авыл хужалыгы һәм эшкәртv сәнәгате хезмәткәрләрен тәбрикләделәр.
Бәйрәмдә хужалыкларнын ин яхшы хезмәткәрләре, игеннәр осталары, терлекчелек һәм vсемлекчелек тармагы хезмәтчәннәре, белемле белгечләр, тәжрибәле житәкчеләр билгеләп vтелде. Алар барысы да, бер элемтәдә эшләп, районнын социаль-икътисади vсешенә vз олешләрен кертеп, уртак эш башкаралар.  Чарада катнашучыларны сәламләv cvзендә Кадошкино районы башлыгы Андрей Викторович Чаткин әйтте: «Кадошкино районындагы агросәнәгать комплексынын авыл хужалыгы һәм эшкәртv сәнәгате хезмәткәрләре бәйрәме авылда яшәvче һәм эшләv-челәрне берләштерә. Авыл хужалыгы хезмәтчәннәре, уныш vстереп, сот һәм ит житештереп, безнен кече Ватаныбызнын азык-толек иминлеген тудыралар...»
Авыл хезмәтчәннәре жиргә тугры булганнары, эшкә намуслы булганнары очен рәхмәткә лаек. Һава шартлары быелгы елны әйбәт дип атау кыен, шуна да карамастан, бортеклеләр унышы әйбәт жыелган, район терлек азыгы белән тәэмин ителгән, авыл хужалыгы оешмаларынын тотрыклы эшләве очен нигез салынган. Тогәлрәк саннарга игътибар итик, 2022 елда район хужалыклары 200 гектардан артык сорvлек жирләрен сореп, чәчv әйләнешенә керткәннәр. Игенчеләр 55 мен тонна ашлык жыеп алган. Район буенча уныш - 27,6 ц/га, хәзерге вакытта тунга 2150 га кvтәрелгән, шунын белән киләсе ел унышына яхшы нигез салганнар. Зур унышларга ирешкән алдынгылыр һәм мактаулылар арасында Рушан Зариф улы Поташов КФХасы, хезмәткәрләре белән бергә, һонәри бәйрәмдә ирешкән унышлар очен бvләкләнде.
Елдан - ел районнын «Мир цветов» жәмгыятчелеге яхшы нәтижәләргә ирешve турында да әйтелде. 2022 елнын 9 аенда 24,1 миллион роза чәчәге киселгән. Авыл хужалыгы продукциясен сатудан кергән табыш 1254 млн.сум тәшкил иткән.
Агросәнәгать комплексында озак еллар намуслы хезмәте очен Россия Федерациясе Авыл хужалыгы министрлыгынын Рәхмәте тvбән-дәгеләргә игълан ителде: ООО «Хорошее дело» тракторчы-машинисты Рәис Ростәм улы Альмяшевка; шул ук оешманын тоягеч машина йортvчесе Марат Каюм улы Еникаевка. Озак еллар тырышып «Мир цветов» чәчәкчесе булып хезмәт иткән Наилә Хәлил кызы Килдеева Мордовия Республикасы Дәvләт Жыелышынын Мактау грамотасы белән бvләкләнде. Ә РМ Хокvмәтенен рәхмәте (Благодарность Правительства РМ) белән Руслан Таһир улы Альмяшев бvләкләнде.
Агросәнәгать комплексында озак еллар намуслы хезмәте очен РМ авыл хужалыгы һәм азык-толек министрлыгынын Мактау грамотасы белән Голнур Исмәгыйль кызы Байбекова (фотода сулдан беренче), жәмгыятчелекнен хезмәтне саклау буенча белгече бvләкләнде.
Мордовия авыл хужалыгы һәм азык-толек министрлыгынын Рәхмәте белән гомерен авыр профессияләрнен берсе булган шоферлыкка багышлаган һәм тырышып хезмәт иткән (ООО «Магма ХД») Фәрит Мобин улы Байбеков бvләкләнә.

Кадошкино муниципаль районы башлыгынын Мактау грамотасы белән тvбәндәгеләр бvләкләнде: Эдуард Каюм улы Айсин, «Транс-М»нын машина йортvчесе; Амир Рауф улы Долотказин, «ИП Долотказин А.Р.»нын шәхси эшмәкәре, Винера Рафаил кызы Мангутова, «Мир Цветов»нын чәчәкчесе.
Бер кечкенә генә районда гына да кvпме татар милләтле кешеләребез туган якларын, Ватаннарын яратып баета. Аларнын һәрберсе турында гел мактау сvзләре генә янгырасын.

**Наилә НАСЫРОВА** *әзерләде,фото «Возрождение» газетасыннан*